# Мәктәп хәбәрчесе

**№3**
**(№6)**
**март**
**2019 ел**

*Түбән Майна урта мәктәбе гәзите*

**Тел. 8 (84344) 4-38-46** **sch1644maina@mail.ru**

**/Укытучы сүзе /**

## Барыбыз өчен дә уртак бурыч

Бала тәрбияләү күп көч һәм вакыт таләп итә. Бу эштә беренче чиратта гаилә тәрбиясе зур роль уйный. “Алтыдагы – алтмышта”, “Оясында ни күрсә – очканда шул була” – ди халык мәкальләре. Соңгы елларда ата-аналар тәрбия мәсьәләләрен күбрәк балалар бакчасы, мәкпәп өстенә генә йөкләп, укыту-тәрбия эшләреннән читләшүе сизелә. Уйлап карасак, тәүлекнең 6-8 сәгатен генә бала бакчада яки мәктәптә уткәрә, ә калган 16-18 сәгате гаиләдә, әти-әни янында уза. Шулай булгач, балага гаилә йогынтысының бернинчә тапкырга көчлерәк икәне аңлашыла.

Әти-әниләр дә, балалар да үз хокукларын яхшы беләләр. Мәсәлән:

- дәүләт стандартларына нигезләнеп бушлай белем алу;
- белем бирү формасын сайлау;
- мәктәптәге китаплардан, мәгълүмат ресурсларыннан һәм уку әсбапларыннан түләүсез файдалану;
- өстәмә белем бирү хезмәтләреннән бушлай файдалану;
- класстан тыш чараларга ирекле рәвештә катнашу;
- һәр фән буенча объектив дөрес билге алу;
- үзенә кулай булган теләсә кайсы уку йортын ирекле сайлау.

Ләкин хокуклар белән беррәттән бурычларны да онытырга ярамый. Менә бурычларны үтәү иң авырларыннан берсе дә инде. Уйлап карыйк әле, без кибеткә барсак, нинди товар аласы килә, нәрсә ошый – шуны алырга хокукыбыз бар. Ләкин товар сайлагач түләү таләп ителә, ул - безнең бурыч. Шуннан соң гына сайлаган товар безнеке була. Шулай булгач, нигә соң безнең белем алуга кагылышлы хокукыбызны беләбез, ә бурычларны онытабыз. Ни өчен дәресне сәбәпсез калдыру, өй эшләренә тиешенчә әзерләнмәү, уку кирәк-яракларын өйдә онытып калдыру, мәктәп формасына салкын караш - укучы өчен нормаль күренеш булырга тиеш.

Укучыларның төп бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

- күңел биреп укырга, программада күрсәтелгән белемнәрне тулысы белән үзләштерергә;
- барлык имтихан, зачетларны, контроль һәм язма эшләрне үз вакытында тапшыру;
- сәбәпсез дәрес калдырмаска;
- дәрес вакытында тыныч булырга;
- өй эшләрен вакытында әзерләп килергә.

Тагын шуны да әйтәсе килә, һәр мәктәпнең үз эчке кагыйдәләре дә бар. Алар белән һәр бала, һәр әти-әни таныш булырга тиеш. Шуларны үтәгәндә генә без башкалардан үз хокукларыбызны таләп итә алабыз.

Сүземне йомгаклап шуны әйтәсе килә: “Киләчәк – бүген төзелә”, диләр. Балаларны киләчәк тормышка әзерләүдә укытучылар белән ата-аналар бергәләп тырышканда гына нәтиҗәсе яхшы булачак. Димәк, балаларыбызның иртәгесе көне ата-аналар һәм укытучылар кулында.

*Рифгать Туктамышев. VII сыйныф җитәкчесе*

## *8 март –*
## *Халыкара хатын-кызлар көне*



Хөрмәтле хатын-кызларыбыз – мәктәптә тәрбияләнүче һәм укучы кызлар, тәрбияче, укытучы һәм гомумән, мәктәптә эшләүче апалар. Барчагызны да ин күркәм бәйрәмнәрнең берсе – Халыкара хатын-кызлар көне белән чын күңелдән тәбрик итәбез! Алдагы көннәрегез шатлык белән тулып торсын, якыннарыгыз Сезне яратып, кадерегезне белеп яшәсен. Язгы кояшның беренче җылы нурлары белән килгән бу бәйрәм бәхет-шатлыклар гына ирештерсен!

*Мәктәптәге барча ир-егетләр*

**/Рәсми хәбәрләр /**

22 март көнне уку елының иң озын өченче чирегe тәгәлләнде. Мәктәптәге 57 укучының 43 енә чирек билгеләре чыгарылды. Бу чирекне гел 5ле билгеләренә мәктәп күләменә бер генә укучы – икенче сыйныфтан **Гафиятуллин Фаил** тәгәлләде. Тагын 20 укучы 4ле-5ле билгеләренә генә өлгерде. Шулай итеп, гомуми нәтиҗәләр буенча, белем сыйфаты **48,8%** тәшкил итте. Әлбәттә, бу күрсәткеч безнең мәктәп өчен бик түбән. Бер генә 3ле белән төшеп калган 6 укучыбыз билгеләрен күтәргән булсалар, чирек уңышлы тәгәлләнгән дип саналыр иде.

23-31 март көннәрендә укучылар язгы каникулларын ял иттеләр. Ләкин чыгарылыш сыйныфлар өчен каникуллар да хезмәт белән узды. 9-11 сыйныф укучылары 27 март – математика, 28 март – рус теле, 29 март – биология фәннәре буенча сынау имтиханнарын тапшырып карадылар. Нәтиҗәләр әлегә билгеле түгел.

***Укыту эшләре буенча директор урынбасары***
***Илдар Сафиуллин***

**/Бәйрәм репортажы/**



## *Нәүрүз мөбарәк булсын!*

Куптәннән килгән гадәт буенча безнең мәктәптә өченче чирек ахырында Нәүрүз бәйрәме уздырыла. Бу бәйрәм фарсы һәм төрки халыкларында бик борынгы заманнардан ук үткәрелеп килгән. Аның вакыты 21-22 март – көн белән төн тигезләшкән чорга туры килә. Нәүрүз – язны каршылап, чәчү эшләре башланыр алдыннан үткәрелә торган халык бәйрәме ул. Ел фасыллары арасында яздан да матуррак, ямьлерәк вакыт юктыр ул. Зәңгәр күктән якты кояш көлә, язның матурлыгына сокланып кошлар сайрый, гөрләвекләр шавы ишетелә. Менә шундый вакытта үткәрелә Нәүрүз бәйрәме.



Быел мәктәпнең Нәүрүз бәйрәме 21 март көнне үтте. Шул көнне безнең авылдан бәйрәм рухы китмәде. Иртәдән үк һәр сыйныф укучылары үзләренең җитәкчеләре белән атларны бизәделәр. Бәйрәм башланыр алдыннан без шул атларны җигеп урам буйлап әйләндек. Атлар белән килешкә тирә-юньгә тәмле төтен исе таралган иде. Карасак, Азат абый самовар куеп җибәргән, ә бер кырыйда Илсур абый үзенең тәмле шашлыгын пешереп тора иде. Шуннан соң башлангыч сыйныф укучылары концерт куйдылар. Аларның биюләре, җыр-шигырь һәм тамашалары бик матур килеп чыкты. Минемчә, Нәүрүз бәйрәменә һәрбер кеше үз өлешен кертә. Кемдер концертта катнаша, кемдер сыерчык оясы ясый, ә кемдер ярминкәдә ясаган әйберләрне сата. Бәйрәм барганда пешекче Рәмия һәм Илсөяр апалар үзләренең коймакларын тәкъдим итте. Кайнар чәй белән коймак – бәйрәмнең иң тәмле мизгеле булды. Башлангыч сыйныфлар чыгышларын тәмамлагач, без үзебезнең сыерчык ояларын күргәзмәгә куйдык. Сыерчык оялары ясаган балаларга мәктәп директоры Рафик абый бүләкләр тапшырды. Бәйрәм чаралары мәктәп ярминкәсе белән тәгәлләнде. Ярминкәдә укучылар үзләре ясаган товарларын саттылар. Узган еллардан аермалы буларак, быел сыерчык ояларын алучы гына табылмады. Аларны ясаган укучылар кире үзләре белән алып китте.



Нәүрүзгә җыелган халык бәйрәмнән канәгать калды. Чөнки мондый күмәк оештырган бәйрәмнәр авыл халкын тагын якынайта, берләштерә. Нәүрүз бәйрәме күңелләребезне күтәреп, анда катнашкан һәркемгә яшәү дәрте өстәде.

***Репортажны Әминә Туктамышева әзерләде***



## *8 март уңаеннан бәйрәм чаралары*

Ел саен мәктәптә Халыкара хатын-кызлар көне төрле чаралар белән уза. Иң элек укучылар хатын-кыз образына багышлап төрле рәсемнәр ясап күргәзмә оештыралар. Рәсемнәрдән күренгәнчә, бу бәйрәм яз бәйрәме буларак кабул ителә. Балалар чәчәк бәйләмнәрен күбрәк ясаганнар. Җиһанга яз сулышы өрелгәнгәдер, күңелләрендә чәчәкләр бөреләнгәнне, яз һавасы яңадан табигатьне уятканын тасвирлаганнар.

2 март көнне балалар бакчасында “Гаилә бәйрәме” уздырылды. Башта балалар әти-әниләре өчен әзерләгән чыгышларын күрсәтте. Аннан соң гаиләләр арасында ярышлар уздырылды. “Гаилә бәйрәме” әниләр һәм бакча хезмәткәрләре әзерләгән бәйрәм табыны белән тәгәлләнде



7 март көнне кичен авылның мәдәният йортында 6-11 сыйныфлар бәйрәмгә багышланган җыр-биюле тамаша куйдылар. Концертның буеннан-буена җырлар да, шигырьләр дә, театрлаштерелгән өзекләр дә безнең иң якын, кадерле затларыбызга – әниләргә багышланган иде. Котлау сүзләре белән алмашынып торган концерт укучыларның якыннарын ял иттерде, бәйрәмнән һәркем канәгать калды.

***Репортажны Сара Насыйрова әзерләде***

## *Майналы Тәрҗемановлар* *\/Күренекле шәхесләр/*



Тарихтан билгеле булганча, 1917 елгы инкыйлабка кадәр балаларга белем бирү дин әһелләренең вазифасына кергән. Безнең Түбән Майна авылында 1857 елдан алып 1920 елларга кадәр авылыбызның рухи тормышы белән татар халкына бик күп күренекле шәхесләр биргән Тәрҗеманилар нәселе вәкилләре җитәкчелек итә. Бу нәселнең тамырлары хәзерге Әлки районына кергән Әнҗерә авылыннан. Нәсел башында торган Тәрҗеман бабай, егет чагында Бохарада укып, заманының зур гыйлем ияләреннән саналган. Авыл картлары Тәрҗеман бабайның күпмедер вакыт Түбән Майнада яшәгәнлеген сөйлиләр иде.

Тәрҗеманилар нәселен Түбән Майна авылында таратучы Шәрәфетдин мулла була. 1857 елда Казандагы дамулла Габделгалләм хәзрәт (Апанай) мәдрәсәсен тәмамлап, имам-хатыйб һәм мөгаллимлек итүгә указ бирелгәннән соң, Шәрәфетдин Тәрҗеманов Түбән Майна авылында муллалык эшен алып бара башлый. Халык телендә аның полковник дәрәҗәсендә саналуы һәм корал йөртергә хокукы булганлыгы турында хәбәрләр калган. Шәрәфетдин мулла 1904 ел ахырында 71 яшендә вафат була.

Шәрәфетдин хәзрәтнең ир балалары барысы да аталары укыган Апанай мәдрәсәсен тәмамлыйлар. Олы улы Минһаҗетдин, 1889 елда указ алып, авылга азанчы һәм сабиан (кече яшьтәге балаларны укытучы) булып кайта. Шул ук елда энесе Бәдретдин дә икенче имам һәм мөгаллим булып хезмәт итә башлый. 1903 елга караган бер документта Бәдретдин хәзрәт авыл мәктәбенең мөдире буларак күрсәтелгән. Бәдретдин мулла җитәкчелегендә 1905-1907 елларда авылда яңа мәчет һәм мәдрәсә биналары төзелә.

Шәрәфетдин мулланың өченче улы Мөхәммәтзәки 1901 елда күрше Иске Әдәмсуы авылының беренче мәхәлләсенә имам итеп чакырыла. Зәки мулла 1906 елда үз мәхәлләсендә таш мәчет салдыра. Хәзер бу бинада Иске Әдәмсуы авылының мәктәбе урнашкан. Бу авыл халкы хәзер дә Зәки мулланы бик укымышлы һәм дәрәҗәле зат буларак искә алалар.

1906 елда мәдрәсә тәмамлап указ алгач, вафат булган әтисе урынына Шәрәфетдин мулланың дүртенче улы Кәшәфетдин кайтып төпләнә. Шушы елдан алып Бәдретдин хәзрәт беренче, ә энесе Кәшәфетдин икенче имам һәм мөгаллим вазифаларын башкаралар. Кәшәфетдин хәзрәт, муллалык итүдән бигрәк, бик актив рәвештә сәяси эшчәнлек белән шөгыльләнә. Аның Дума сайлауларында катнашуы турында хәбәрләр калган.

XIX гасырның икенче яртысыннан алып күршедәге Шәмә һәм Чуаш Ялтаны авылларындагы мөселман халкы Түбән Майна мәхәлләсенә караган. 1913-1915 елларда Шәмә авылында Бәдретдин мулланың “Мөхәммәдия” һәм “Иж-Буби” мәдрәсәләрендә укып кайткан улы Мисбахетдин имам булып тора. Шулай итеп, Тәрҗемани хәзрәтләрнең эшчәнлеге Түбән Майнаны гына түгел, тирә-күрше авылларны да колачлый.

Халыкның җайга салынган тормышы инкыйлабтан соң зур үзгәрешләр кичерә. 1918 елның февралендә авылда чуалышлар булып уза. Авыл советы рәисе халыкның икмәген талау белән кәсеп итә башлаган ярлылар комитеты вәкилләрен кыйнауны оештыра. Шуның икенче көнендә авыл җыены әлеге рәисне төшереп, аның урынына Кәшәфетдин мулла сайлана, абыйсы Бәдретдин сәркәтип итеп билгеләнә. Авыл советы мөселманчалаштырып “Шура” дип үзгәртелә. Дүрт көннән соң авылга кызыллар отряды килеп, Шура яклылар белән кызыллар арасында кораллы бәрелеш була. Атышлар вакытында Кәшәфетдин мулла яраланып, бер айдан соң вафат була. Ул вакытта авырып яткан Минһаҗетдин мәзинне гаиләсе кар базына төшереп качырган була. Ул шуннан үпкәсенә салкын тидереп, 1921 елның сентябрендә үлеп китә. Бәдретдин мулла атарга дип бастырган җирдән качып китеп, күпмедер вакыт Биләрдә һәм Баганалы авылында яшеренеп тора. Авылга кайткач тиф белән авырып 1923 елда вафат була. Шулай итеп, илдә барган фетнәле вакыйгалар Тәрҗеманиларның Майнадагы нәселенә зур зыян сала. (Рәсемдә – Кәшәфетдин Тәрҗеманов, 1905 ел)

## ***Дәрестән тыш эшчәнлек*** ***/ Безнең уңышлар /***

Ай башында узган **“Салават күперенең барлык төсе”** дип аталган район конкурсының “Оригиналь рәсем” номинациясендә **Галимова Нәзилә** белән **Нукина Виктория**, “Фотоконкурс” номинациясендә **Шичкина Карина** һәм **Әхмәтҗанова Лилия** I урыннарны яуладылар. (Остазлары – **Зарипова Зөлфия Дамир кызы**) **“Россия сувенирлары”** дип аталган кул эшләре күргәзмәсе конкурсында **Залиева Вәсилә**, **“Кәгазь могҗизасы”** конкурсында “"Папье-маше" номинациясендә **Нукина Виктория** I урыннарны алдылар. (Остазлары – **Хәйруллина Рузилә Әдһәм кызы**)



«**Без бергә**» балалар халык иҗаты Республика фестиваль-конкурсының муниципаль этабында катнашып «Иң яхшы күргәзмә композициясе» номинациясендә **Хәйруллина Рузилә**, “Иҗади гаилә” номинациясендә **Яхина Рузилә** белән **кызы Ләйлә**, “Җыр” номинациясендә **Сафиуллина Динә** II урыннарга ия булдылар.

### ***Спорт ярышлары***

16 март көнне Норлат шәһәрендә **самбо** көрәше буенча 2005-2006 елгы яшүсмерләр арасында уздырылган Республика беренчелегендә **Камалов Илдус** II урынны алды. (Тренер – **Камалов Илһам Илгизәр улы**)

## /Укучылар иҗаты/

### *Яз җиткәндә*

Яз җиткәнен белгертеп
Тама тамчы түбәдән.
Кара карга, сыерчыклар
Килгән икән көтәннән.

Язның күңелле вакыты
Безнең каникул җиткән.
Барлык бала тырыш укып,
Көткәндер аны күптән.

Яратамын мин уйнарга
Кар эрегән урында.
Ничек икән алып чыгыйм
Дусларымны урамга.

Уйнаучылар сирәк хәзер
Урамда, саф һавада.
Компютеры, телефоны
Якынрак шул аларга.

Әти-әни яшь чагында
Урамда гел уйнаган
Кич булса да, ач булса да
Уеннан һич туймаган.

Нинди генә уеннарны
Белми алар хәзер дә.
Уйнап үскән иптәшләре
Әле дә хәтерләрдә.

Безнең истә нәрсә калыр
Утырсак гел өйдә без.
Чыгыйк әле болыннарга
Барыйк дуслар, әйдәгез.

Чыгыйк дуслар, бергә уйныйк
Кыска чор ул – балачак.
Бергә уйнап үскән вакыт
Шунда истә калачак.

***Әминә Туктамышева***

## /Котлыйбыз!/



Март аенда туган көннәрен билгеләп үтүче бакча төркеменнән Хәбибрахманова Асияне, укучылар Морадимов Илсурны, Сафиуллина Зөлфирәне, Гыйззәтуллина Алияне, Сәгъдиева Таңсылуны, Шәфиков Әнисне, Хөснуллина Алияне туган көннәре белән котлыйбыз. Ныклы сәламәтлек, укуларында тырышлык телибез. Барча теләкләрегез дә тормышка ашсын дуслар!

## *«Оста куллар» түгәрәге*

## / Кызыклы әңгәмә /

Безнең мәктәптә күп еллардан бирле "Оста куллар" түгәрәге эшләп килә. Бу түгәрәккә йөрүче укучылар төрле иҗади конкурсларда катнашып, алдынгы урыннарны алып киләләр. Хәбәрчеләребез Зөлфирә белән Вика, бу эшнең башында торган Рузилә апаларыннан интервью алды.



**- Рузилә апа, сез кайчаннан бирле "Оста куллар" түгәрәген алып барасыз?**

- «Оста куллар» түгәрәге мәктәп күләмендә берничә еллар дәверендә эшләп килә. Ә мин әлеге түгәрәкне бары тик икенче ел гына җитәклим.

**- Түгәрәккә йөрүче кызлар күп төрле һөнәрләр үзләштерә. Сез үзегез бу һөнәрләрне кайда өйрәндегез?**

- Минем әнием бик оста бәйли, тегә, чигә иде һәм мине дә бу эшләргә өйрәтеп калдырды. Бала чактан ук әнием янәшәсенә утырып, аның кул эшләре белән кызыксына идем. Бераз үсә төшкәч, аңа оекбаш, башмак, башлык, бияләйләр, шәл кырыйлары бәйләшә башладым. Ә инде рәсемнәр ясау сәләте әтиемнән күчкәндер дип уйлыйм. Әти безнең балта остасы, һәм бик матур рәсемнәр ясый иде.

**- Сез укучыларга өйрәткән кул эшләре аларга киләчәк тормышларында да кирәк булыр инде?**

- Үземнән чыгып әйтәм – кул эшләрен белү тормышымда бик кирәк булды. Кул эшләре белән шөгыльләнү акыл һәм сәламәтлек өчен дә файдалы. Бәйләү, рәсем ясау, ябыштыру көндәлек тормыш мәшәкатьләреннән арындырып, күңелгә психологик комфорт тудырырга ярдәм итә, чуалган фикерләрне тәртипкә китерә. Кул эшләре белән мавыгучыларның бармакларының тактик тойгылары, хәтта интуициясе дә үсештә була. Психологлар әйтүенчә, яңадан-яңа шөгыль белән мавыгучыларның гомерләре озынрак һәм кәефләре күтәренкерәк була.

**- Түгәрәк эшчәнлегендә сез халык иҗатына да зур игътибар бирәсез.**

- Безнең халыкта элек-электән кызлар үзләре теккән, чиккән әйберләр белән бирнә сандыгы туплаганнар. Шулай итеп кыз балалар йолаларны аңлап үсә. Халык алдында үзен уңган кыз буларак таныта. Минемчә, бу гореф-гадәт бүгенге көндә дә актуаль һәм аны торгызырга кирәк.

**- Укучылар түгәрәккә теләп йөриме?**

- Әйе, түгәрәккә кызлар теләп йөриләр. Чөнки алар биредә кул эшләрен генә өйрәнеп калмыйлар, иптәшләре белән аралашалар, бер-берсенә киңәшләр бирәләр, үзләре өчен ачышлар ясыйлар. Кул эшләре темасы, минемчә, аралашу өчен иң кызыклы...

**- Хәзерге вакытты түгәрәктә ниләр эшлисез?**

- Үткән елны кызлар белән бәйләргә өйрәндек. Төрле башлыклар, берет, челтәрләр, курчаклар бәйләдек. Ә быелгысы елны чигү эшләре һәм башка күп төрле һөнәрләр белән шөгыльләнеп киләбез. Хәзер кызларыбыз бик остарып киттеләр, Аллага шөкер. Районда үткәрелкән кокурсларда катнашып, алдынгы урыннар алдылар. Аларның киләчәктә дә зурдан-зур уңышларга ирешүләрен телим.

**- Түгәрәкнең киләчәген ничек күзаллыйсыз?**

- Киләсе буын укучыларның да, кул эшләренә өйрәнеп үсүләрен телим. Хәзерге вакытта Европа илләрендә табигый материалдан ясалган көндәлек куллану әйберләре бик кыйммәт тора. Соңгы вакытта безнең төбәктә дә кул эшләре белән шөгыльләнүчеләр күбәеп китте. Бәлки киләчәктә кызларыбызның шөгыльләре, тормышларында бизнеска әйләнеп китәр. Шәхсән үземә килгәндә, теләге булган укучыларны киләчәктә дә өйрәтермен, Алла бирсә.

**- Кызыклы әңгәмәгез өчен рәхмәт, Рузилә апа.**

***Әңгәмәне Зөлфирә Сафиуллина белән Виктория Нукина үткәрде***


**Газетаны гамәлгә куючы – Түбән Майна урта мәктәбе**
**Мөхәррир – Фәнүзә Гафиятуллина**
**Редколлегия әгъзалары:**
Әминә Туктамышева
Виктория Нукина
Зөлфирә Сафиуллина
Алия Гыйззәтуллина
Нәзирә Әхматова
Рузилә Мөхәммәтова
Сара Насыйрова